ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
27.04.2026

**КАРАР**
№ 8

Урта Тигәнәле ав.

**Башкарма комитетның 16.01.2016ел, №1 «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 18.03.2026 ел, №09/13-09/1370 тәкъдимнәрен игътибарга алып, карар бирәм:

1. Башкарма комитетның 16.01.2016ел,№1«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында» карары преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» «2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына,«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына туры китереп,Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларын юллау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгы белән төзелгән Килешү нигезендә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К.Хәмәтвәлиев**